# ТАТАР ДИАСПОРАСЫ ФОРМАЛАШУНЫҢ ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

**Искәндәр Аяз улы Гыйләҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан, Кремль ур., 18,
gilyzov1958@gmail.com

Мәкаләдә Идел һәм Урал буенда сибелеп утырган татарларның таралып урнашуы һәм төрле тарихи чорларда БДБ илләрендә һәм чит илләрдә татар диаспорасының төрле төркемнәре барлыкка килүенең төп үзенчәлекләре һәм сәбәпләре гомуми планда карала. Моңа табигый-географик, икътисади, сәяси, милли-дини факторлар тәэсир иткән. 1552 нче елдан соң татарларның таралып урнашуына хөкүмәт сәясәте дә җитди йогынты ясаган. Татарларның Россия территориясендә таралып урнашуы күп очракта табигый сәбәпләргә бәйле булган, һәм гасырлар дәвамында татарларны бүлгәләү максаты белән хакимият тарафыннан рәсми рәвештә турыдан-туры басым ясалуын күрмибез. Шул ук вакытта бу мөмкинлек игътибардан бөтенләй читтә калмаган дип фаразлыйбыз, чөнки дәүләткә бердәм, икътисади, сәяси яктан көчле һәм мәдәни яктан үсеш алган православие динендәге Россиягә җитди көндәш һәм оппозиция булырлык татар этносын саклау файдалы булмаган.

**Төп төшенчәләр:** Идел һәм Урал буе татарлары, диаспора, диаспоралар төркеме, сибелеп утырган халык, эмиграция, таралып урнашу.

«Диаспора» сүзе халыкара лексиконга грек теленнән кергән, һәм ул «таралып яки сибелеп урнашу» мәгънәсендә кулланыла. Галимнәр һәм сәясәтчеләр бу исем белән Фәләстиннән күчеп киткән яһүд халкы вәкилләрен атый башлаганнар. Бүгенге көнгә аның эчтәлеге сизелерлек дәрәҗәдә киңәйгән. «Диаспора» яки «диаспора төркеме» дип без үзенең төп этник территориясеннән күчеп киткән, башка географик төбәктә төпләнгән һәм ул төбәктә этник азчылык хәлендә яшәүче төрле халык вәкилләрен атыйбыз. Ләкин фәндә әлегә кадәр «диаспора» төшенчәсенең галимнәр тарафыннан кабул ителгән төгәл аңлатмасы юк. Шулар арасыннан берсенә тукталыйк: «Диаспора – это значительная часть народа (этнической общности), живущая вне страны ее происхождения и образующая давно сложившуюся, высокоорганизованную, сплоченную, устойчивую, хорошо укоренившуюся и ставшую необходимой для принимающей страны, группу» [1: 34].

«Диаспора» төшенчәсен кулланганда, төгәл тарихи нигез булуын истә тоту зарури. Бу фикерне татар халкы мисалында ачыклыйк. Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларның барысын да «диаспора» дип атарга мөмкин. Ләкин бу тарихи һәм сәяси яктан дөреслеккә туры килеп бетми. Хәзерге Русия Федерациясендә яшәүче татарларның күбесе борынгы чорлардан ук үзләренең этник формалашу территорияләрендә яшиләр, алар биргә күчеп килмәгән, без аларны автохтон халык дип санарга хаклы. Ә Әстерхан, Себер, Пермь, Башкортостан татарларын яки мишәрләрнең төп төркемнәрен «диаспора» дип атарга мөмкин. Шуңа күрә аларны бары тик формаль күрсәткечләргә генә нигезләнеп «диаспора» дип атау дөрес түгел[1].

Бу мәкаләдә сүз татар диаспорасы тормышында актуаль булган мәсьәләләр турында бармаячак, бәлки диаспора формалашуның төп алшартлары, сәбәпләре һәм үзенчәлекләре хакында кайбер фикерләрем белән уртаклашырга телим. Төгәлрәк әйтсәк, мәкаләдә түбәндәге төп сорау куела: Ни өчен татар халкы Русия Федерациясендә яшәүче башка халыклар белән чагыштырганда иң дисперс, ягъни иң чәчелгән, иң таралган халыклардан санала? Бу таралуның тамырларын ничек табарга? Татарлар белән янәшәдә, бер төбәктә яшәгән халыклар (чуваш, мари, мордва, удмурт һ.б.), татарлардан аермалы буларак, күмәкләшеп яши, ә татар төрле вакытта, төрле шартларда бөтен дөньяга таралган. Ни өчен

[1] Бүгенге сәяси вәзгыятьтә Татарстан Республикасы үзен барлык төбәкләрдә һәм илләрдә яшәүче татар милләте вәкилләренең берләшүе өчен җаваплы үзәк итеп таныта, Татарстан Республикасы Конституциясенең 14 маддәсендә бу җаваплылык закон төсен кабул иткән: «Татарстан Республикасы Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтә». Татарстаннын төрле диаспора төркемнәре белән аралашу мәсьәләләре хакында кара:[2].

тарихта шулай килеп чыккан соң? Әлбәттә, бер мәкаләдә генә мондый катлаулы һәм күпьяклы сорауга тәфсилле, тулы җавап бирү җиңел түгел, шуңа күрә мин максатымны проблеманы куюда һәм аның чишелешендә кайбер юнәлешләрне билгеләүдә күрәм.

Идел-Урал татарлары тарихында, Русия дәүләтендә яши башлаганчы ук, озак гасырларга сузылган дәүләтчелек тарихы булуы билгеле, һәм инде борынгы чорда, урта гасырларда дисперс яшәү барлыкка килү өчен кайбер алшартлар күзәтелә.

Беренче меңьеллыкка кадәр барлык төрки халыкларның борынгы бабалары күчмә тормыш алып барган һәм Үзәк Азиянең чиксез далаларында күченеп йөргән. Күчмә халыкның тормыш рәвеше, һичшиксез, мобильлек, хәрәкәтчәнлек таләп итә, ул һәрвакыт гомер иткән урыннынан кузгалып китәргә әзер булырга тиеш, шулай ук аның көнитеше табигать шартларына бәйле булган. Әгәр дә халык хәрәкәт итми, яңа көтүлекләр тапмый икән, ул үзенең төп матди байлыгы булган мал-туарын тукландыра, саклап кала алмый, аны һәлакәт көтә. Шундый тормыш рәвеше төркиләрдә гасырдан-гасырга сакланып килгән, аның нигезендә икътисади һәм мәдәни традицияләр барлыкка килгән, һәм табигый ки, бу тормыш рәвеше халыкларның этник психологиясенә дә көчле йогынты ясаган.

Яңа урынга күчеп урнашуга әзерлек кешеләрдән тәвәккәллек һәм кыюлык таләп иткән, чөнки яңа урында яхшырак климатик-географик шартлар булуына бернинди гарантия булмаган. Җитмәсә, дала зонасында башка күчмә халыклар яшәвен дә онытырга ярамый – килмешәкләрне беркем дә көтеп тормаган, яңа килгән халык конкрет төбәктә электән яшәүчеләр белән уртак тел табарга, аралашырга, ә кайвакыт сугышырга, көрәшергә мәҗбүр булган.

Димәк, инде борынгы гасырларда ук төрки халыкларның уртак бабалары тормышында бу мәкаләнең темасы өчен әһәмиятле үзенчәлек күрәбез: алар хәрәкәтчәнлек белән аерылып торганнар, һәм бу тормыш рәвеше этник психологияләренә дә сеңеп калган.

Безнең эраның беренче гасырларында төрки халыкларның беренче дәүләтләре дә барлыкка килә, аларның кайберләрендә төркиләр инде утрак тормышка да күчә башлыйлар. Бу үзгәрешкә аларны яңадан табигый-географик шартлар мәҗбүр итә. Мәсәлән, Урта Идел яки Төньяк Кавказ шартларында тулысынча күчмә тормыш алып бару мөмкин түгел. Тормыш рәвешен үзгәртү төркиләр өчен элекке традицияләрнең бетүен, җимерелүен белдергән, һәм, әлбәттә, бу үзгәреш җиңел булмаган, чөнки ул күнегелгән тормыштан баш тартуны аңлаткан. Мондый күренешләр Хәзәр каганлыгында да, Идел Болгар дәүләтендә дә күзәтелә. Төркиләр бу дәүләтләрдә инде күбрәк утрак тормышта игенчелек, һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнә башлыйлар [3].

Хәзерге Идел-Урал татарларының бабалары төзегән борынгы дәүләтләрдән безнең өчен бигрәк тә Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы әһәмияткә ия. Билгеле булганча, бу дәүләтләрнең икътисади тормышында сәүдә, шул исәптән чит илләр белән алып барылган сәүдә аеруча зур урын алып торган [4]. Европаның иң зур һәм мөһим сәүдә артериясе – Идел сәүдә юлы, бу дәүләтләрнең кулында булуы сәүдә үсеше өчен гаҗәеп киң мөмкинлекләр биргән һәм аларның казналарына зур табыш китергән. Сәүдә мөнәсәбәтләре Идел буе Болгар дәүләтен, Алтын Урданы, Казан ханлыгын Европадан алып Кытайга кадәр төрле илләр белән бәйләгән. Урта гасырларда Идел буе дәүләтләре Урта Азия, Кавказ, рус кнәзьлекләре белән уңышлы сәүдә алып барган, кайбер илләрдә сәүдәгәрләрнең тотрыклы колонияләре дә барлыкка килгән, алар башка илләрдә тамыр җибәрә башлаган, нәтиҗәдә яңа этник берәмлекләр формалашкан. Уңышлы барган сәүдә татарларның бабаларында халыкара аралашуга әзерлек тудырган, бу шартларда алар Европа һәм Азия илләре арасында арадашчы булуны яхшы аңлаганнар. Сәүдә белән шөгыльләнү шул ук вакытта кешеләрдә яңа холык сыйфатлары барлыкка китерә – алар аралашучан, кыю, кирәк чакта хәйләкәр, компромисcларга әзер булырга, башка халыкларның гореф-гадәтләрен, психологиясен, традицияләрен, мәдәниятен аңларга, ихтирам итәргә тиеш булганнар.

Урта гасырларда ук, Алтын Урда яки Казан ханлыгы чорларында, Евразия халыкларының төрле төбәкләрдә урнашуына халыкара хәрби-сәяси мөнәсәбәтләр көчле йогынты ясый башлый. Ул халыкара бәйләнешләр һәрвакыт тыныч булмаган. Хәрби каршылыклар, тартышлар тормышның табигый бер күренеше булып торган. Хәрби бәрелешләр еш кына дәүләтләрдә эчке каршылыкларның кискенләшүе белән янәшә барган. Гадәттә бу эчке конфликтларны тышкы дошманнар үстереп торган. Нәтиҗәдә, мондый сәяси вәзгыятьләр барышында, эчке һәм тышкы

каршылыклар нык кискенләшкән чорларда конфликтларда катнашкан аерым төркемнәр, аеруча җиңелгәннәрне, үз илләрен ташлап китәргә мәҗбүр булган. Алар илләренә дошман яки дустанә мөнәсәбәтләре булмаган дәүләтләргә юл тотканнар. Аларны, гадәттә, җылы кабул иткәннәр, соңрак шул «сәяси-хәрби эмигрантларны» сәяси дошманнарга каршы көрәштә файдаланганнар. Мондый күренешләр Урта гасыр Европасы өчен типик булган. Мисал итеп Алтын Урда, Мәскәү һәм Бөек Литва князьлекләре арасындагы мөнәсәбәтләрне китерергә мөмкин. Нәкъ шундый сәяси чорда татар диаспорасының иң борынгы төркеме булган Польша-Литва татарлары оеша башлый [5].

Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулангач, татарлар өчен яңа тарихи шартлар пәйда була. Алар, дәүләтчелекләрен югалтып, бөтенләй башка, үзләре өчен чит булган дәүләт кысаларында буйсынган хәлдә яши башлый. Фаҗигале хәлдә булсалар да, алар җайлашу чорын узып сакланып калалар, Рус дәүләтенә хәрби, дипломатик һәм сәяси даирәләрдә шактый әһәмиятле һәм файдалы хезмәтләр күрсәтә башлыйлар. Берничә мисалга тукталып үтим.

Ливон сугышы вакытында (1558–1583) Мәскәү гаскәрендә хезмәт иткән 33 407 сугышчы арасында 5854 йомышлы татар булуы билгеле. 1612 елда полякларга каршы көрәш алып барган Кузьма Минин һәм Дмитрий Пожарский ополчениесенә дә күп татарлар кушылганы мәгълүм. 1613 елда Михаил Романовны патша итеп игълан иткән Земский собор утырышларында татар морзалары катнашкан, аларның җидесе Собор кабул иткән патшаны сайлау грамотасына кул куйган булган [6]. XVI йөз ахыры – XVII йөз башларында татарлар рус гаскәренең 10%ын тәшкил иткәннәр, 1651 елда бу сан 6,5%ка кадәр төшкән [7].

Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорында татарларның Рус дәүләте һәм рус тормышында эз калдырырлык сәяси, мәдәни йогынты ясаганын, димәк, рус дәүләтчелеге формалашуы һәм үсешенә кабатланмас өлеш керткәнен[1], Казан яулангannан соң, Мәскәү Алтын Урда җирләрен үз кулы астына «җыю» процессын башлап җибәргәнен [11: 130], димәк, Алтын Урданың сәяси мирасына дәгъва кылганын исәпкә алсак, татарлар яңа сәяси шартларда рәсми рус хөкүмәтеннән шактый җитди сәяси һәм икътисади ташламалар алырга хаклы булган. Ләкин, билгеле булганча, алай барып чыкмаган. Яулап алынган Урта Идел территориясендә яшәгән халыкларга карата алып барылган рәсми сәясәт, бер яктан, татар җәмгыятенең иҗтимагый деформациясенә, ә икенче яктан, татарларның бу төбәкне ташлап, төрле тарафларга күченеп китүенә китергән. Рус дәүләте тарафыннан Урта Идел халыкларына карата XVI-XIX урталарында алып барылган сәясәт хакында иң төгәл анализ Андреас Каппелер тарафыннан бирелгән [11], бу турыда безнең тарафтан да язылды [12]. Дәүләт законнарында андый конкрет максат куелмаган булса да, реаль тормышта нәкъ шундый күренешләр күзәтелгән.

XVIII йөз башына татарларның югары катлавы – йомышлы татарлар, ягъни феодал-җирбиләүчеләр, әлеге сәясәт нәтиҗәсендә, тулысынча таркалып бетә. Бу фактны Рус хөкүмәтенең, сәяси оппозиция оешуына юл ачмас өчен, руслар өчен куәтле, барыбер ышанычсыз булган сәяси конкурентны юлдан алу өчен уйланып эшләнгән адымы дип бәяләргә мөмкин. Җир биләмәләрен югалткан татар морзалары («чабаталы морзалар») сәүдәгәр яки руханилар сафларын тулыландырган [13].

Законда күченеп урнашуларга артык күп киртәләр булмаганын исәпкә алсак, Рус дәүләте шартларында зур территорияләрдә татарларның урнашуы табигый процесс булып бәяләнергә хаклы. Һәм тормышта шулай килеп чыккан да: XVI-XVIII йөзләрдә татарлар, бигрәк тә игенчеләр, гади халык, тормыш алып бару өчен яңа мөмкинлекләр эзләп, төньяк, көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш юнәлешләренә, тарихи этник территорияләреннән ерагаеп, актив рәвештә күченеп урнаша [14: 257-297].

Димәк, рус дәүләтенең XVII-XVIII йөзләрдәге иҗтимагый-икътисади сәясәте татарларның сибелеп яшәвендә төп

[1] Н.М.Карамзиннан башлап рус тарих фәнендә Рус дәүләтенә Алтын Урда һәм татар халыкларының йогынтысы нигездә тискәре яктан бәяләнә, бу «традиция», кызганычка каршы, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Ләкин кайбер зур рус тарихчылары (С.М.Соловьев, Н.И.Костомаров, В.О.Ключевский, М.Н.Покровский) бу йогынтыга уңай бәя биргән, һич булмаса аның негатив нәтиҗәләрен артык күпертеп тасвирламаган. Бу турыда кара: [8] Казан ханлыгы тарихын өйрәнгән күренекле галим М.Г.Худяков шулай ук бу мәсьәләгә тукталып узган һәм Рус дәүләтенең төзелешенә һәм аның мәдәни үсешенә татарлар уңай йогынты ясаганын ассызыклаган. Кара: [9: 235-241]. Шулай ук кара: [10].

факторларның берсе булып тора. Без бер закон текстында да татарларны таркату, бүлү, шуңа нигезләнеп хәлсезләндерү турында укый алмасак та, дәүләтнең барлык адымнары да шундый нәтиҗәгә китерә.

Шул ук чорда Русиянең дини сәясәте ислам динен буйсындыруга һәм мөмкин кадәр тиз арада татарларны чукындыруга юнәлгән булган [15]. Мөселманнарда бу сәясәт табигый рәвештә каршылык, протест уяткан, ул актив һәм пассив формаларда чагылган. Пассив протестның бер төре – якын яки ерак төбәкләргә (Кырым, Казахстан яки Урта Азия) качып яки күченеп китү булган [14; 16].

Әлбәттә, дини сәясәт икътисади сәясәт белән тыгыз бәйләнештә алып барылган. Икътисади сәбәпләр татарларның Русия империясе территориясе буйлап күченү өчен шулай ук җитди нигез булып торган. Мәсәлән, XVIII йөзнең беренче яртысында дәүләт тарафыннан салым җыю сизелерлек дәрәҗәдә арттырылганнан соң, татарларның, массакүләм рәвештә, Урта Идел төбәгеннән Көньяк Урал, ә тора-бара Казахстан һәм Урта Азия якларына күченүләре билгеле [14: 276-279].

Бу мәкаләнең төп мәсьәләсен аңлау өчен, рус хөкүмәтенең татар сәүдәсенә нисбәтле алып барган сәясәтен мисал итеп китерүне бик тә урынлы дип саныйм, чөнки ул күченү процессларына турыдан-туры тәэсир иткән. XVII-XVIII йөзләрдә Рус дәүләте сәүдә итүче татарларга чын һәм, ни гаҗәп, ихлас симпатия белдереп торган. Әлбәттә, бу очракта Идел-Урал төбәгендә борынгы чорларда ук формалашкан сәүдә традицияләре, сәүдәнең югары үсеше күз уңыннан ычкындырылмаган. Табигый ки, Рус дәүләте бу традицияне үз файдасына кулланган. Без моны чын мәгънәсендә прагматик сәясәт дип билгели алабыз. Аңлашыладыр, сәүдә, бер яктан, сәүдәгәрләрнең үзләренә табыш, икенче яктан исә, дәүләт казнасына акча һәм товар китергән. Бу беренче карашка гына шулай тоела. Шул ук вакытта билгеле бер дәрәҗәдә тышкы сәүдә, бигрәк тә Урта Азия илләрендә алып барылган татар сәүдәсе, бу тарафларда Русия дәүләтенең сәяси йогынтысын көчәйткән. Татар сәүдәгәрләре Урта Азия юнәлешендә рус сәяси-хәрби экспансиясен әзерләүдә ихтыярсыз катнашкан булып чыгалар. Рус христиан сәүдәгәрләре өчен бу юнәлешнең, нигездә, ябык булганлыгын исәпкә алсак, хөкүмәтнең татар сәүдәгәрләренә бу төбәктә нәтиҗәле эш итү өчен төрле ташламалар бирүе һәм татар сәүдәсенә юл ачуы тулысынча аңлашыла. Мисал өчен Казанда һәм Оренбургта татар сәүдә бистәләренең барлыкка килүен, сәүдә итүче татарларга аерым ташламалы статус бирелүен, хәтта рус сәүдәгәрләре белән конфликтлар килеп чыкканда, администрация татарларга булышлык итүен искә төшерергә мөмкин[1].

Шиксез, элекке җирбиләүчеләр (йомышлы татарлар) дә сәүдә белән шөгыльләнүгә игътибар һәм кызыксыну белән караган, чөнки алар өчен катлауланган икътисади вәзгыятьтә сәүдә яңа матди һәм иҗтимагый мөмкинлекләр ачкан. Ә татарларның актив тышкы сәүдә операцияләренә кушылуы төрле төбәкләргә яки илләргә барып кайту белән генә чикләнмәгән, алар бу төбәк яки илләрдә төпләнгән һәм сәүдә колонияләре дә оештырып җибәргән. Моның ачык мисалы – 1744 елда Оренбург шәһәре янында Каргалы (Сәет) бистәсе оештырылу. Императрица Елизавета Петровна указы буенча бирегә, Бохара һәм Хива белән сәүдә алып бару өчен, 200 казан татары гаиләсенә күченеп урнашырга рөхсәт бирелә [19: 89-90]. Татарлар биредә сәүдәне шул хәтле уңышлы оештырып җибәрәләр ки, XVIII йөзнең 60 нчы елларына хәзерге Казахстан территориясендә алып барылган вак сәүдә тулысынча татарлар кулына төшә, XVIII йөз ахырына Урта Азия илләре белән Русиянең Оренбург аша алып барылган барлык сәүдә операцияләренең дүрттән өч өлешен татар сәүдәгәрләре үз контрольләре астында тота [20: 37].

XIX йөз Русия империясе һәм аның халыклары тормышына шактый күп һәм тирән үзгәрешләр китергән. Бу чорда татарларның мобильлеге һәм татар мохитендә күзәтелгән миграция процесслары узган гасыр белән чагыштырганда кимемәгән. Аларның сәбәпләре күпчелек очракларда икътисад белән бәйләнгән. Урта Идел төбәгендә татар игенчеләренең күпчелеге җир азлыгыннан җәфаланган [21], күп очракта мондый игенчеләр авылны ташлап китәргә мәҗбүр булган. Алар, бәхет эзләп, традицион колонизация төбәкләренә (Урта яки Көньяк Урал) [14: 280], сәнагать үскән төбәкләргә (Донбасс, Урал, Әзәрбәйҗан), ә кайчакта чит илләргә дә юл тотканнар[2].

[1] Татар бистәләре турында кара: [17]; Казан ханлыгын Рус дәүләте тарафыннан яулануы нәтиҗәләре турында кара: [18]; Русия законнарында татар сәүдәсе һәм татар сәүдәгәрләре хокуклары турында кара: [19].

[2] XIX йөз ахырында татарларның Төркиягә күченеп китүләре бигрәк тә ачык мисал булып тора – бу күченүләр өчен төп этәргеч булып 1891 елгы ачлык

Татарларның башка төбәкләр яки илләргә күчеп китү сәбәпләре арасында дәүләт тарафыннан алып барылган милли-дини сәясәтне һәм татар җәмгыятендә күзәтелгән иҗтимагый-сәяси үзгәрешләрне дә атарга кирәк. Нәкъ менә XIX йөздә татар фикер ияләре үз милли тамырлары, татар халкының килеп чыгышы турында җитди уйлана башлый, татарларда милли идеология формалаша, татар җәмгыятендә яңарыш чоры башланып китә. Бу вакыттагы рухи эзләнүләрнең бер юнәлеше булып төркичелек, ягъни төрки халыкларның берлеге идеологиясе тора [22]. Билгеле бер дәрәҗәдә төрки халыкларны берләшергә өндәгән берлек фикере, славян халыкларының уртак идеологиясе булган панславизм пропагандасына үзенчәлекле җавап булып каралырга мөмкин. Төркичелекнең барлыкка килүе, әлбәттә, Русия империясендә күзәтелгән гомум иҗтимагый-сәяси тормышның активлашуы, төрки халыкларның (бигрәк тә, казан һәм кырым татарларында һәм әзәрбәйҗаннарда) милли үзаң үсеше һәм формалашуы белән бәйле.

Бу идеология киң масштабта төрки халык вәкилләрен Төркиягә күчеп китәргә турыдан туры өндәмәсә дә, аның XIX йөз ахыры – XX йөз башындагы күченүләргә нигез булып торганлыгы аңлашыла. Бу үзенчәлек аеруча рус-төрек сугышлары вакытында төрки халыкларга карата алып барылган милли-дини сәясәт кискенләшкәндә ачык сизелгән[1].

XX йөз башында гомум Русия масштабында барган сәяси вакыйгалар чит илләрдә татар диаспора төркемнәре формалашуына хәлиткеч йогынты ясаган. Бу чорда без инде татарларда сәяси эмиграция дигән күренеш барлыкка килә дип әйтә алабыз, бу эмиграциянең төп юнәлеше булып Госманлы дәүләте (Төркия) тора. Соңрак, 20–30 нчы елларда, Төньяк-Көнчыгыш Кытай, Япония һәм Кореяга килеп урнашкан татарлар да, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Төркиягә күченеп бетәләр [16: 104-108].

Димәк, кайбер башка дисперс халыклар (мәсәлән, әрмәннәр) белән чагыштырганда, татарларда диаспора төркемнәре дулкынсыман, хәтта сикерешләр рәвешендә оешкан. Шулай итеп, Русия территориясендә һәм кайбер чит илләрдә татар диспорасы төркемнәре барлыкка килгән. Һәрбер очракта диярлек бу оешуның һәм үсешнең конкрет үзенчәлекләре булган. Аларның кайберләрен аерым атап китәргә мөмкин.

Польша-Литва татарлары инде туган телләрен күптән онытсалар да, диннәрен һәм үзаңнарын саклап кала алганнар. Аларның оешуы Алтын Урда чорында башланып киткән. XIV йөз ахырында 30 меңгә якын кеше, төрле сәяси һәм хәрби сәбәпләр аркасында, Алтын Урдадан Бөек Литва кнзязьлегенә күчеп китәргә мәҗбүр булган. Бөек князь Витовт аларны бик җылы кабул иткән, күбесен яңа дәүләткә хәрби хезмәткә алган һәм җир биләмәләре биргән. Ислам дине үсеше өчен бернинди киртә куелмаган – татарлар үз диннәрендә калган. 1410 елда татарлар мәшһүр Грюнвальд сугышында катнашып, Тевтон ордены гаскәрен җиңүгә зур өлеш кертккәннәр. Сәяси вәзгыять кискен үзгәреп торса да, татарлар тормышы гасырдан-гасырга хәрби хезмәт белән бәйле булган. Алар Бөек Литва князьлегендә, Речь Посполитая дәүләтендә, XVIII йөз ахырыннан Речь Посполитая бәйсезлеге бетерелгәч, Русия империясе составында хезмәт иткәннәр. XX йөз башында, мәсәлән, Русия гаскәрендә Польша-Литва татарларыннан егермегә якын генерал хезмәт иткәне билгеле. Татар диаспорасының бу төркеме XX йөзнең 20-30 елларында чын мәгънәсендә мәдәни, рухи яңарыш һәм күтәрелеш чорын кичерә. Аны Польша дәүләтенең яңадан бәйсезлеген кайтаруы белән бәйләү дөрес булыр. Бу кыска вакыт эчендә татарларда музейлар, китапханәләр ачыла, аларның тарихын, мәдәниятен фәнни өйрәнү башланып китә, төрле иҗтимагый оешмалар һәм бердәм дини идарә (мөфтият) оештырыла. Ләкин Икенче бөтендөнья сугышы, кызганычка каршы, бу Ренессанс чорын рәхимсез рәвештә туктата. Дөрес, соңгы елларда без, Польша һәм Литва дәүләтләрендә, 20–30 еллар күтәрелеше белән чагыштырып булмаса да, татар тормышының яңадан иҗтимагый-мәдәни активлашуы хакында әйтә алабыз. Бүген Польшада биш меңгә якын, Литвада өч мең ярым тирәсе татар яшәве билгеле. Аларның чит мохиттә татар, мөселман булып яшәүләренең төп сере – дини үзаңны саклауда. Ислам дине алар өчен төп саклану факторы булып калган [24: 710-711; 5].

Төркия республикасында бүгенге көндә, элекке Советлар Союзы территориясеннән кала, иң зур татар диаспорасы яши дип исәпләнә. Диннәре бер, телләре бик якын булу сәбәпле, бирeдә яшәүче татарлар бик тиз төрекләшәләр.

---

һәм аннан соң башланган икътисади кыенлыклар торган. Кара: [16: 103–104].

[1] Кырым сугышы (1853-1856) вакытындагы вакыйгаларны мисал итеп китереп була. Дин кардәшләренә каршы сугышырга теләмәгән бер төркем татарларның Урта Азия һәм Төркиягә күчеп киткәннәре билгеле. Бу турыда кара: [23: 370].

Шулай да, бүгенге көндә Төркиядә, кайбер белгечләр фикеренчә, 20-25 мең татар яши. Татарларның Госманлы дәүләтенә күченүләре XIX йөз ахырына карый һәм дини, икътисади сәбәпләр белән аңлатыла. Билгеле булганча, солтан Габделхәмид II вакытында Русиянең төрле төбәкләреннән биш меңгә якын татар Төркиягә күчеп китәргә теләкләрен белдерәләр һәм ике яктан да рөхсәт алалар. Күчкәннәрнең күпчелеге игенче була, Төркиягә килгәч, алар, берничә авылга нигез салып, биредә игенчелек белән шөгыльләнүләрен дәвам итәләр. Соңрак бу татарларга сәяси эмигрантлар (алар арасында мәшһүр шәхесләр – Садри Максуди, Йосыф Акчура, Габделбари Баттал, Гаяз Исхакый, Әхмәт Тимер һ.б.), Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышының хәрби әсирләре, Япония, Корея һәм Кытайдан килгән татарлар да кушыла. Бүген дә ассимиляция процессы көчле булуга карамастан, Төркиядә яшәүче татарлар, милли үзаңнарын тулысынча югалтмыйча, тарихи ватаннары белән багланышлар урнаштырып яшиләр [25: 714–715].

Финляндия татарлары күпсанлы төркем булмасалар да, бөтен татар дөньясы өчен милли үзаңны саклауда үрнәк булып торалар. Шунысы игътибарга лаек: бу илгә күчкән татарлар заманында чит илгә китмәгәннәр, чөнки Финляндия территориясе 1809 елдан 1917 елга кадәр Русия империясе составына кергән. Бирегә, нигездә, Түбән Новгород губернасы авыллары сәүдәгәрләре күчкән. Алар эчке сәүдә максатлары белән фин шәһәрләрендә урнашалар. 1917 елгы сәяси вакыйгалардан соң, Финляндия бәйсезлек алгач, татарлар, чит илдә калып, тарихи ватаннарыннан тулысынча аерылалар. Бу изоляция тора-бара (бигрәк тә, 1930–1940 елларда СССР һәм Финляндия аралары нык кискенләшкәннән соң) көчәя төшә. Татарлар чит мохиттә татар булып сакланып калу юлларын эзли башлыйлар һәм, ахыр чиктә, бу юнәлештә телне, динне, гореф-гадәтләрне саклауда, балаларга тәрбия бирүдә үрнәк булырлык уңышларга ирешәләр. Бүген Финляндия татарлары саны бер меңнән артмаса да, алар үз милли үзаңнарын, диннәрен, телләрен саклап киләләр, башка татарларны да шундый юлдан барырга өндиләр [26].

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Маньчжурия, Япония һәм Кореядәге татарларның зур күпчелеге Төркиягә күченеп китә. Ләкин бу илләрдә XX йөзнең 20-30 елларында яшәгән татарлар татар эмиграциясе тарихында сәяси һәм мәдәни активлыклары белән тирән эз калдырган. Татарларның Ерак Көнчыгышка килүләре Кытай территориясендә Русия тимер юлы төзелеше белән бәйле. Гражданнар сугышы вакытында бирегә Совет хөкүмәтенә каршы торган күпсанлы татар эмигрантлары килә. Иҗтимагый оешмалар оеша, мәчетләр төзелә, мәктәпләр ачыла, шәһәрләрдә бар яктан да көчле татар колонияләре барлыкка килә. Алар үзара элемтәләр урнаштырып, иҗтимагый-сәяси тормышларын берләштерәләр – 1934, 1935 елларда Кобе һәм Мукден шәһәрләрендә оештырылган татар корылтайлары бердәм Милли идарә төзи. Бу орган татар милли тормышын үз карамагында тотып, эмиграциядә яшәүче татарларны берләштерүне максат итеп куя.

Ерак Көнчыгыш татарлары тормышында Гаяз Исхакыйның роле гаять зур, аның тырышлыгы белән «Милли байрак», «Яңа япон мөхбире » кебек әһәмиятле газета-журналлар чыга башлый. Кызганычка каршы, Икенче бөтендөнья сугышы, Кытайда коммунистик режим барлыкка килү Ерак Көнчыгышта татар тормышын тулысынча үзгәртә – татарлар яңадан Төркия, АКШ, Австралия илләренә күчәргә мәҗбүр булалар [27].

Югарыдагы мисаллар, минемчә, татарларның төрле илләрдә диаспора төркемнәре оешуының, аларның биредә алып барган тормышлары төрле шартларда барганлыгын күрсәтә. Шулай да бер уртак үзенчәлекне ассызыклау кирәк: татарлар яңа шартларга яраклашырга, авыр булса да үз мәдәниятләрен, телләрен, диннәрен сакларга тырышканнар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Русия территориясендә һәм чит илләрдә татар диаспорасы икътисади, сәяси, милли-дини сәбәпләр аркасында формалаша. Татарлар Рус дәүләтенең барлыкка килүенә һәм үсешенә зур өлеш керткән, бигрәк тә XVI–XVII йөзләрдә. Шуңа күрә Рус хөкүмәтеннән алар ташламалар, соңрак булса да дәүләт идарәсендә үзләренә лаеклы урын алырга хаклы булганнар, әмма Рус дәүләте аларны бу даирәдән кысрыклаган гына. Татарлар, куелган шартлар нәтиҗәсендә, иҗтимагый яктан таркалып, демографик яктан чәчелеп, сибелеп яши башлаган. Әлбәттә, Русия территориясенең төрле төбәкләрендә татарларның урнашуы табигый сәбәпләр аркасында барган, Русия рәсми законнарында татарларны төрле якка тарату максаты беркайчан да ачыктан ачык куелмаган. Ләкин хөкүмәт бу

моментны һичбер вакыт игътибар үзәгеннән ычкындырмаган – үзен христиан иле дип исәпләгән Рус дәүләтенә икътисади, сәяси һәм мәдәни яктан көчле, бердәм, җитмәсә мөселман диненә тугры калган татар милләте кирәк булмаган, чөнки бу очракта татарлар православ Русиягә көчле конкурент була алганнар.

Шулай итеп, татарларга, үз иҗтимагый бердәмлекләрен саклап кала алмаган кебек, бер территориядә күмәкләшеп яшәү дә мөмкин булмаган, алар күченеп, таркалып, бүленеп көн күрергә мәҗбүр булган.

**Әдәбият**


1. *Колосов В.А., Галкина Т.А., Куйбышев М.В.* География диаспор на территории бывшего СССР // Общественные науки сегодня. 1996. № 1. С. 34.
2. *Исхаков Д.М.* Татарская диаспора в России // Звезда Поволжья. 2000. 17; 18-24 мая.
3. *Артамонов М.И.* История хазар. Л., 1962. С.235, 239; *Фахрутдинов Р.Г.* Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984. С. 31-36; *Хузин Ф.Ш.* Волжская Булгария в домонгольское время (X – начало XIII веков). Казань, 1997. С. 71-75.
4. *Валеев Р.М.* Волжская Булгария: торговля и денежно-весовые системы IX – начало XIII веков. Казань, 1995. С. 30-75; *Худяков М.Г.* Очерки по истории Казанского ханства. Казань, 1991. С. 217-223; *Хузин Ф.Ш.* Волжская Булгария в домонгольское время (X – начало XIII веков). С. 85-92.
5. *Гришин Я.Я.* Польско-литовские татары. Наследники Золотой Орды. Казань, 1995. С. 10-16; *Он же*: Польско-литовские татары: Взгляд через века. Казань, 2000. С. 5- 8; *Он же*: Татарский след в истории Литвы и Польши (XIV-XIX вв.). Казань, 2005. С. 6-24.
6. *Сенюткина О.Н.* Татары-мусульмане на службе Отечеству // Рамазановские чтения. № 1. 2006. Нижний Новгород. С. 177-182.
7. *Алишев С.Х.* Социальная эволюция служилых татар во второй половине XVI-XVIII вв. // Исследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода. Казань, 1984. С. 63; *Чернов А.В.* Вооруженные силы Русского государства в XV-XVII вв. М., 1954. С. 95, 167.
8. *Якубовский А.Ю.* Золотая Орда. Очерк истории Улуса Джучи в период сложения и расцвета в XIII–XIV вв. Л., 1937. С.193-201.
9. *Худяков М.Г.* Очерки по истории Казанского ханства. М.: Инсан, 1991. 320 с.
10. *Spuler B.* Die Goldene Horde und Rußlands Schicksal, in: Anfänge des Moskauer Staates (=Wege der Forschung, Bd. CCCXL). Darmstadt, 1977. S. 361-378.
11. *A.Kappeler*. Rußlands erste Nationalitäten: Das Zarenreich und die Völker der Mittleren Wolga vom 16, bis. 19. Jh. Köln–Wien, 1982. 571 p.
12. *Гилязов И.А.* Политика царизма по отношению к татарам Среднего Поволжья во второй половине XVI-XVIII вв. // Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995. С. 242.
13. *Гилязов И.А.* Помещики Тевкелевы в XVIII – начале XIX вв. К вопросу об исторических судьбах татарского феодального класса // Классы и сословия в России в период абсолютизма. Куйбышев, 1989. С. 77-86; *Губайдуллин Г.С.* К истории разложения феодального класса у приволжских татар // Известия Восточного факультета Азербайджанского университета: Востоковедение. 1928. Т. 2. С. 1-26; *Нестеров В.А.* Нерусские помещики и их крестьяне в Среднем Поволжье (вторая половина XVI-XVII вв.) // Вопросы аграрной истории Среднего Поволжья (XVII – начало XX вв.) Саранск, 1979. С. 10-28; *Степанов Р.Н.* К вопросу о служилых и ясачных татарах // Сборник аспирантских работ: Право, история, филология. Казань, 1964. С. 52-70; *A.Kappeler.* Rußlands erste Nationalitäten: Das Zarenreich und die Völker der Mittleren Wolga. 1982. S. 245-259.
14. Исхаков Д.М. Динамика численности и особенности размещения татар в Волго-Уральском регионе в XVI – начале XX вв. // Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995. С. 257-297
15. Гилязов И.А. Ислам и православие в Среднем Поволжье после 1552 г. // Die Geschichte Rußlands im 16. und 17. Jahrhundert aus der Perspektive seiner Regionen. Hrsg. von Andreas Kappeler. Wiesbaden 2004. S. 310-321; *Загидуллин И.К.* Христианизация татар Среднего Поволжья во второй половине XVI–XVII вв. // Ученые записки Татарского гуманитарного института. 1997. № 1. С. 111-165; *Ислаев Ф.Г.* Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: От конфронтации к терпимости. Казань, 2001. 220 с.; *Он же:* Православные миссионеры в Поволжье. Казань, 1999. 127 с.; Исламо-христианское пограничье: Итоги и перспективы изучения. Казань, 1994. 207 с.; *Макаров Д.М.* Самодержавие и христианизация народов Среднего Поволжья (XVI-XVIII вв.). Чебоксары, 2000. 280 с.; *Фаизов С.Ф.* Государственно-исламские отношения в Поволжье и Приуралье. Уфа, 1995. 114 с.; *Он же*: Ислам в Поволжье VIII-XX вв. М., 1999. 76 с.
16. Татары и Татарстан. Справочник. Казань: Таткнигоиздат, 1993. С. 98-99.
17. Гилязов И. Татарские слободы города Казани во 2-ой половине XVI – середине XIX вв. // Das mittlere Wolgagebiet in Geschichte und Gegenwart / Klaus Heller; Herbert Jelitte (Hrsg.) Frankfurt am Main;Berlin;Bern; New York; Paris; Wien: Lang,

1994 (=Beiträge zur Slavistik, Bd. 22). S. 33-46; Татарские слободы Казани: Очерки истории. Казань, 2002. 304 с.

18. *Гилязов И.А*. Социальные и экономические последствия завоевания Казанского ханства // Татарский народ после 1552 года: потери и приобретения. Казань, 2003. С. 144–153.
19. *Ногманов А.И.* Самодержавие и татары. Очерки истории законодательной политики второй половины XVI-XVIII веков. Казань, 2005. С. 77-94.
20. *Михалева Г.А*. Торговые и посольские связи России со среднеазиатскими ханствами через Оренбург. Ташкент: Фан, 1982. 92 с.
21. *Смыков Ю.И.* Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма. М., 1984. С. 108-109; Халиков Н.А. Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX – начала XX вв. М.,1981. С. 15-16.
22. *Мухамметдинов Р.Ф.* Зарождение и эволюция тюркизма: Из истории политической мысли и идеологии тюркских народов (Османская и Российская империи, Турция, СССР, СНГ 70-е гг. XIX в. – 90-е гг. XX в.). Казань, 1996; *Червонная С.М., Гилязов И.А., Горошков Н.П.* Тюркизм и пантюркизм в оригинальных источниках и в мировой историографии: исходные смыслы и цели, парадоксы интерпретаций, тенденции развития // Ас-Алан. 2003. № 1(10). С. 3-478.
23. *Литвинов П.П.* Антитатарская политика царизма в Средней Азии и Казахстане // Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995. 496 с.
24. Татарская диаспора в Литве // Tartarica. Атлас. Казань – Москва – Санкт-Петербург: Изд-во «Феория», 2006; *Закиров Р.З.* Татары в меняющемся мире: Очерки этнополитической истории в XX – начале XXI вв. Казань, 2006. С. 174-179.
25. Татарская диспора в Турции // Tartarica. Атлас. Казань – Москва – Санкт-Петербург: Изд-во «Феория», 2006. 888 с.
26. *Заһидуллин И.К.* Татарларның Финляндия Бөек кенәзлегенә күченү сәбәпләре һәм биредәге тормышларының кайбер сәхифәләре // Чын мирас. 2013. № 11(23). 10-17 б.; *Надиров И.Н.* Татары в Финляндии // Материалы Материалы по истории татарского народа. Казань: Таткнигоиздат, 1995. С. 468-485; Татарская диаспора в Финляндии // Tartarica. Атлас. Казань– Москва – Санкт-Петербург: Изд-во «Феория», 2006. С. 715.
27. Татарская диаспора в Китае // Tartarica. Атлас. Казань – Москва – Санкт-Петербург: Изд-во «Феория», 2006. С. 717; Татарская диаспора в Японии // Tartarica. Атлас. Казань – Москва – Санкт-Петербург: Изд-во «Феория» 2006. С. 718; Закиров Р.З. Татары в меняющемся мире. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. С. 188-191; *Usmanova L.* The Turk-Tatar Diaspora in Northeast Asia, Transformation of Consciousness. A Historical and Sociological Account Between 1898 and the 1950 s. Tokyo: Rakudasha, 2007. 367 p.